**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«05» 12 2022 ел Яр Чаллы № 3811

«Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм Тукай муниципаль районының су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 ноябрендәге 3720 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган чыгымнар күләмен билгеләү методикасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган «Граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган чыгымнар күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 19 августындагы 865 номерлы һәм 2022 елның 15 сентябрендәге 1007 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм Тукай муниципаль районының су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең

хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 ноябрендәге 3720 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм Тукай муниципаль районының су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәнең II бүлегендә 1 таблицаны «хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары» яңа редакциядә бәян итәргә:

1 таблица

| № | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 19862,00 |
| 2 | Оператив дежур | 15279,00 |

1.2. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм Тукай муниципаль районының су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәнең III бүлегендә 8 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм Тукай муниципаль районының су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәнең III бүлегендә 10 пунктны «Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләү, аларны яшерү һәм ачу, шулай ук шифрлар белән эшләү өчен өстәмәләр» яңа редакциядә бәян итәргә:

Даими нигездә дәүләт серенә рөхсәте булган хезмәткәрләргә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 18 сентябрендәге «Даими нигездә дәүләт серенә рөхсәте булган гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрнең хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 573 номерлы һәм 1997 елның 27 декабрендәге «Россия Федерациясендә шифрлау хезмәте хезмәткәрләрен социаль яклау турында» 1639 номерлы карарлары нигезендә елына вазыйфаи окладның 2,5%-ы күләмендә айлык процент өстәмәсе түләнә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 январеннан үз көченә керә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин